572

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## 1993 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

"Татарстан Республикасында бюджет төзелеше һәм бюджет гамәлләре турында" Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I статья. Президент тарафыннан тәкъдим ителгән 1993 елга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджет проектын исәпкә алырга.

2 статья. 1993 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, табышка салым өлеше, физик затлардан керем салымнары өлеше һәм башка керемнәр исәбенә барлыкка килүен билгеләргә.

3 статья. Татарстан Республикасының 1993 елга республика бюджетында керемнәр килере 174510049 мең сум икәнен исәпкә алырга, шул исәптән түбәндәге төп чыганаклар буенча:

/мең сумнарда/

| | |
|---|---|
| Өстәлгән бәяләргә салым | - 44900000 |
| Акцизлар | - 13872000 |
| Нефть буенча акцизлар | - 48048000 |
| Табышка салым | - 21970346 |
| Физик затлардан кеременәргә салым | - 3724288 |
| Хосусыйлаштырудан керемнәр | - 916200 |
| Мөлкәткә салым | - 221325 |

| | |
|---|---|
| Җир асты байлыклары өчен түләү | - 7107587 |
| Җир өчен түләү | - 634421 |
| Башка төрле салымнар, җыемнар һәм башка керемнәр | - 643690 |
| Бәяләрне көйләү фонды | - 32061000 |
| Түбәндәге бюджетлардан керә торган средстволар | - 411192 |

4 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 1993 елда районнар һәм шәһәрләр бюджетларына түбәндәгеләрне күчерүне хәл итәргә тиеш:

- предприятиеләрдән, берләшмәләрдән һәм оешмалардан кергән табышка салым табышка салына торган салымның 32,0 процентын тәшкил итә, түбәндәгеләр моңа керми: Әлмәт шәһәренеке - 8%, Чаллы шәһәренеке - 31%, Түбән Кама шәһәренеке - 8%, Азнакай районыныкы - 7%, Әлмәт районыныкы - 3%, Бөгелмә районыныкы - 14%, Сарман районыныкы - 8%, Баулы районыныкы - 11%, Азнакай шәһәренеке - 20%, Лениногорск шәһәренеке - 16%;

- физик затлардан керемнәргә салым тулысынча, түбәндәгеләрнеке моңа керми: Әлмәт районыныкы - 10%, Түбән Кама шәһәренеке - 60%, Азнакай районыныкы - 40%, Әлмәт шәһәренеке - 37%, Лениногорск шәһәренеке - 90%, бу әлеге территорияләрнең бюджетына керә торган салым төрләреннән исәпләнә.

- предприятиеләр мөлкәтенә салым тулысынча.

5 статья. Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 1993 елга агымдагы чыгымнар буенча ассигнованиеләр күләменең өске чиген - 132104550 мең сум, бюджет үсеше буенча 36140935 мең сум күләмендә расларга.

6 статья. Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 1993 елга ассигнованиеләрне 168245485 мең сум күләмендә түбәндәге

574



максатларга юнәлтергә:

/мең сумнарда/

| | Барысы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | агымдагы чыгымнар бюджеты | үсеш бюджеты |
| Халык хуҗалыгын финанслауга, шулардан | 80I42899 | 57263378 | 2287952I |
| агросәнәгать комплексына | 29673664 | I0667664 | I9006000 |
| - ягулык сәнәгатенә | 6I000 | 6I000 | - |
| - торак коммуналь хуҗалыгына | 608000 | - | 608000 |
| - сәламәтлек саклауның хуҗалык органнарына | I280000 | I280000 | - |
| - дәүләт кино фондына | I07000 | I07000 | - |
| - Таткинопрокатка | 66400 | - | 66400 |
| - Төзелеш һәм архитектурага | 53700 | - | 53700 |
| - Татавтотранспортка | 5I4545I | 444545I | 700000 |
| - Татарстан газына | I400000 | I400000 | - |
| - көйләүле бәяләр буенча сатыла торган бәяләргә дотация | 6369000 | 6369000 | - |
| - Горький тимер юлының Казан бүлекчәсенә | 576000 | 576000 | - |
| - "Татарстан һава юлларының" Казан авиация предприятиесенә | 250000 | 250000 | - |
| - Казан елга портына | 400000 | 400000 | - |
| - Чаллы елга портына | 70263 | 70263 | - |
| - тапшырылган терлек продукциясенә дотация | 30000000 | 30000000 | - |
| - җир өчен түләүләргә чыгымнар | 63442I | - | 63442I |

Λ

| | | | |
|---|---|---|---|
| - Урман хуҗалыгы министрлыгына | 2530000 | I637000 | 893000 |
| - ТТК өчен торак йортлар төзелешенең бәясе үсешен компенсацияләүгә | 495000 | - | 495000 |
| - экология фондына бүленгән суммалар | 423000 | - | 423000 |
| Җәмгыяви өлкәне финанслауга | 2I394940 | I7983526 | 34II4I4 |
| шулардан: | | | |
| - халык мәгарифенә | 5384297 | 4724297 | 660000 |
| - мәдәнияткә, шул исәптән ТРыннан читтә яшәүче татар халкына хезмәт күрсәтүгә - 270000 | 3569034 | 2308828 | I260206 |
| - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 459I78 | 459I78 | - |
| - телевидение һәм радиога | 525229 | 458093 | 67I36 |
| - сәламәтлек саклауга | 89I3708 | 7737636 | II76072 |
| - санэпид күзәтүгә | 908376 | 808376 | I00000 |
| - физик тәрбиягә һәм спортка | 66000 | 66000 | - |
| - җәмгыяви тәэминатка | II3678I | I03878I | 98000 |
| - фәнгә | 35I337 | 30I337 | 50000 |
| - яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне финанслауга | 8I000 | 8I000 | - |
| Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарын тотуга | I379406 | I25I406 | I28000 |
| Халыкны җәмгыяви яклау буенча чараларга | 4580000 | 4580000 | - |
| Балаларга пособиеләр һәм компенсацияләргә түләүгә | I7979 | I7979 | - |
| Бәяләр үзгәрешенең индексына бюджетның кагылгысыз чыгымнарын тәгаенләштерү өчен средстволар резервы | I6000000 | I6000000 | - |
| Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фонды | 479625 | 479625 | - |
| Төрле түләүләр һәм башка чыгымнар | 36507II | 35007II | I50000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Капитал салулар, шул исәптән җимерек тораклар - 4000000 | 9272000 | - | 9272000 |
| Нефть ташый торган флот проекты дирекциясенә | 300000 | - | 300000 |
| Район бюджетларына бирелә торган дотацияләр | 3I027925 | 3I027925 | - |

7 статья. Дәүләт хакимияте һәм дәүләт идарәсе органнарын тотуга чыгымнарны I379406 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән: /мең сумнарда/

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Югары Советын, аның Президиумын, республиканың Югары Советы Секретариатын | I700I0 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутатлык вәкаләтләрен үтәү белән бәйле чыгымнарны каплауга | I2000 |
| Татарстан Республикасы Югары Советы сессияләрен үткәрү белән бәйле чыгымнар | I2530 |
| Татарстан Республикасы Президенты һәм вице-президенты, Татарстан Республикасы Президенты Советы һәм Президент каршындагы башка консультатив органнар, Президент аппараты эшчәнлеген финанслау буенча чыгымнар | 7247I |
| Конституция күзәтүе комитетын | 22I5 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт /парламент/ тикшерүе комитетын | 22979 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетын | 8I855 |
| Татарстан Республикасы министрлыкларын, ведомстволарын һәм аларның органнарын | 907699 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының даими вәкилиятләрен: | |
| Мәскәү шәһәрендәге | 33327 |
| Үзбәкстан республикасында һәм БДБнең башка илләрендәге | 26000 |
| Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын | 38320 |

8 статья. Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында кредит-финанс һәм бюджет-салым мөнәсәбәтләре хакында шартнамә төзегәнче, Россия Федерациясе бюджетыннан Татарстан Республикасына тотыла торган гамәлдәге чыгымнарны каплау өчен 1993 елда Россия Федерациясе бюджетына 36 млрд.сум күләмендә акча күчерүне билгеләргә.

9 статья. Татарстан Республикасы республика бюджетыннан 1993 елда районнар һәм шәһәрләр бюджетларына халыкның җәмгыяви тәэминаты дәрәҗәсен тигезләү өчен дотацияләр, шулай ук гамәлдәге бәяләр системасы шартларында төбәкләр арасында керемнәрнең тигез бүленмәвенә бәйле компенсацияләр түләүгә 31027925 мең сум күләмендә акча бүленә, шул исәптән:

/мең сумнарда/

| | |
|---|---|
| Аксубай | 839462 |
| Актаныш | 1055720 |
| Алексеевск | 691364 |
| Апас | 684674 |
| Алабуга | 573968 |
| Арча | 1297717 |
| Балтач | 989969 |
| Буа | 772880 |
| Балык Бистәсе | 832222 |
| Биектау | 732388 |
| Зәй | 30920 |
| Зеленодол | 829661 |
| Кама Тамагы | 521223 |
| Кукмара | 1070835 |
| Кайбыч | 489884 |
| Лаеш | 731529 |

| | |
|---|---|
| Лениногорск | 331047 |
| Мамадыш | 948765 |
| Менделеевск | 65640 |
| Минзәлә | 374392 |
| Мөслим | 639501 |
| Октябрь | 69668 |
| Питрәч | 579280 |
| Саба | 660059 |
| Спасс | 736797 |
| Тәтеш | 854475 |
| Тукай | 100196 |
| Теләче | 514525 |
| Түбән Кама | 1267317 |
| Чирмешән | 463766 |
| Чистай | 595889 |
| Чүпрәле | 836394 |
| Ютазы | 301605 |
| Югары Ослан | 644382 |
| Яңа Чишмә | 294163 |
| Әтнә | 450465 |
| Әгерҗе | 557280 |
| Әлки | 789191 |
| Алабуга шәһәре | 52259 |
| Зеленодол | 431904 |
| Казан | 6324549 |

<u>10 статья.</u> 1993 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты нисбәтләнмәвенең чиген аның күзалланган керемнәренең 17%ы күләмендә билгеләргә.

II статья. Татарстан Республикасының Милли банкына 1993 елда гамәлдәге исәп системасын, Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетларының керемнәре үтәлешен сакларга. Бюджетларның касса үтәлеше буенча гамәлләре, комиссия түләүләре алынмыйча, барлык банклар тарафыннан башкарыла.

I2 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына кирәк очракларда өстәлгән бәяләргә салым һәм табышка салым буенча ташламалар бирүне рөхсәт итәргә, бу хакта квартал саен Татарстан Республикасы Югары Советына мәгълүмат бирергә.

I3 статья. 1993 елга барлык предприятиеләргә һәм оешмаларга предприятиеләр мөлкәтенә салым буенча ставкаларны салым салына торган базадан I процент күләмендә билгеләргә, моңа Дәүләт милкендә һәм җирле милектә, республика Профсоюзлар Советы милкендә торучы оборона комплексы предприятиеләре, һава һәм су транспорты предприятиеләре, шифаханә - курорт һәм сәламәтләндерү учреждентеләре керми, аларның салым ставкалары 0,5 процент күләмендә билгеләнә.

I4 статья. "1993 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законын кабул итү мизгеленнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 5 марты,
№ I769-XII